


Җир өстендә канлы сугыш кабатланмасын өчен,

Ятимнәрнең күз яшьләре таммасын өчен

Ныгытабыз илебезне без тыныч хезмәт белән.


(Ә. Исхак)



# Тема: Тиңдәш иярүле күп иярченле кушма җөмлә.

Максат: Тиңдәш иярүле күп иярченле кушма җөмлә турында төшенчә формалаштыру

Балалар аякка баскач, Фәрит үзе гаилә корып җибәргәч, әнисе акчадан бөтенләй баш тартты. (Ф. Садриев)



Шул кызың булмаса, аның әйбәт кияве булмаса, ялгызың ни эшләр идең?(В.Нуриев)

Күңелләрең синең боекканда,
Сусаганда җаның җырларга,
Юлларга чык. (Ф.Яруллин)

Бер үк  төрле иярчен җөмләләр, ягъни тиңдәш иярчен  җөмләләр бер баш җөмләгә ияреп килсәләр, мондый җөмләләр **тиңдәш иярүле иярченле кушма җөмләләр** дип аталалар.



Өй эше.

- Күп иярченле кушма җөмләләргә синтаксик анализ ясау тәртибен белергә. (мәҗбүри)
- Тиңдәш  ияргүле иярченле кушма җөмләләргә 3 мисалны Ф.Садриевның "Рәхмәт эти" әсәреннән эзләп язарга.
- Тиңдәш  ияргүле иярченле кушма җөмләләр кулланып "Әтием" темасына хикәя язарга.